
*МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ*
*“ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БУА ШӘҺӘРЕ 5 НЧЕ ГИМНАЗИЯ“*

***№2НОЯБРЬ-ДЕКАБРЬ, 2018***

# ТАМЧЫ



## Бәйрәм белән, кадерле әниләр!

Россия Федерациясендә **Әниләр көне** 1998 нче елдан бәйрәм итеlә. Россия президенты Б Н. Ельцинның 1998 нче елның 30 нчы гыйнварендәкабул ителгән карары белән бу көн ноябрьнең соңгы якшәмбесендә билгеләп үтелә.

Бәйрәмнең төп максаты-әниләрнең дәрәҗәсен тагын да югары күтәрү. Безнең гимназиядә бу бәйрәмгә аеруча игътибар бирелә. Быел да укучыларыбыз Әниләр көненә зур тырышлык белән әзерләнделәр: рәсем күргәзмәсендә катнаштылар, дивар газеталары чыгардылар.Берни- чә көн дәвамында , төрле төркемнәргә бүленеп , укучылар әниләренә бәйрәм концерты күрсәт-теләр.

Башлангыч сыйныф укучылары да әниләрен бәйрәмгә чакырдылар. Бәйрәм төрле җыр-бию, шигырьләр белән үрелеп барды.

7а, 7б сыйныф укучыларының Әниләргә багышлап үткәргән бәйрәме дә бик күңелле үтте.Укучылар үзләренең төрле юнәлеш буенча осталыкларын күрсәттеләр.

**Кадерле әниләребез!** Изге бәйрәм уңаеннан иң җылы һәм ихлас котлауларыбызны кабул итегез. Барлык әниләргә, әбиләребезгә, апа-сеңелләргә ныклы сәламәтлек, озын гомер, бәхет телибез.





*кебек, минем дә телем"әннә", сүзе белән ачылган. Әнием минем бик сабыр, тыйнак кеше. Әниемнең исеме -Лилия. Бу исем "чәчәк" дигәнне аңлата. Әниемнең йомшак куллары, ягымлы тавышы миңа шатлык китерә. Мин әниемә кулымнан килгәнчә булышырга, аны борчымаска тырышам. Әнием миңа дәресләремне әзерләгәндә дә булыша: аңламаган сорауларыма да сабыр гына җавап таба, файдалы киңәшләрен дә бирә".*

***Заһретдинова Ләйсән,***

*8-б сыйныф*

*өйдә тәмле ис таралган була. Әнием инде тәмле-тәмле ризыклар пешереп куярга да өлгергән!Без аның белән тәмләп чәй эчәбез, серләребез белән уртаклашабыз. Ял көннәрендә без саф һавада йөрергә яратабыз. Әнием мине һәр кичне назлап йоклата, ә иртән «кызым» диеп сөеп уята. Нинди зур бәхет! Ярый әле, әнием, янәшәмдә син бар! Әнием, мин сине бик яратам! Сиңа иң изге теләкләремне генә телим".*

***Аббазова Эльвина,***

*4-б сыйныфы*

*янәшәмдә син бар! Көннәрем син булганга аяз, төннәрем ай-йолдызлы, якты. Салкыннарда күңел җылыны биреп җылытасың, безнең өчен ял димисең, һәрвакыт хезмәт итәсең.*

*Син безне кешеләргә карата шәфкатьле, ягымлы булырга, һәркемгә ярдәм кулын сузарга әзер торырлык иттереп үстерергә тырышасың. Рәхмәт, әнием, барысы өчен дә зур рәхмәт!"*

***Закирова Ләйлә***

*8-б сыйныф*

*Урман – кырларыбызга ямь өстәп, туган ягыбызга кыш килде. Кыш үзенең кар- буранннары, салкыннары белән үзенчәлекле. Кыш көнен без көтеп алабыз, чөнки кыш көне без урамда уйнарга яратабыз: кар бабай ясыйбыз, кар атышлы уйныйбыз, чаңгыда йөрибез,чана шуабыз. Тиздән Яңа ел бәйрәме җитә. Без өйдә чыршы бизибез. Кыш бабайдан бүләкләр көтәбез.*

***Аббазова Эльвина, 4-а сыйныф***

**ышкы … оман**

*ы. Т… ч кына кар ява. ларн… дык та, урманга кы … ан бик матур. … ту… киләннәр. Безгә целле … рәхәт. Без кичкә еп шу… к.*

***ә, 2-… йныф***



Елның иң тылсымлы **Яңа ел** бәйрәмен Кыш бабайдан башка күз алдына китереп булмый. Бөтенроссия Кыш бабаеның Бөек Устюг шәһәрендә яшәвен һәммәбез дә белә. Анда барып , теләкләр теләргә һәркем дә булдыра алмый. Ә бит безнең үзебезнең дә Кыш бабаебыз бар ! Ул Арча районының Яңа Кырлай авылында яши.

Кыш бабай резиденциясе 3нче декабрьдән 29 гыйнварга кадәр эшли.



**Декабрь аена халык телендәге сынамышлар**


*Декабрьдә кар аз булса, җәй коры килә.
*Декабрьдә кара каргалар күренә икән, кыш җылы була.
*Карсыз декабрь — коры язбилгесе.
*Декабрь башында көчле бураннар, кар яуса, июнь башында яңгырлар була.
* Декабрьгә җир туңса, кар көртләре булса, уңыш уңа.
* Декабрь җиллеикән, март җылыбула.

*...Кар яуганда, тәрәзәдәнкүзләремнеалмыйм. Өйдәкүңелсезмиңа. Урамгачыгасыкилә. Әмматәрәзәгәрәсембулыптөшкәнаксакаллы Кыш бабайкүзкысып, шаянелмаеп: "Урамдасалкын, колак-борыннарыгызныөшетермен", − дипәйтәсыман.Шулай да кайбер балалар урамга чыкмыйча түзмәгәннәр. Алар барыбер тимераяк, чаңгы-чана шуа бирәләр, кар атышып уйныйлар, кар бабай ясыйлар, тау өяләр, тауны су белән катыралар. Шулайитепсуыкныүртиләр. Ә уалаларнытагын да катыракчеметә.*

***Әхмәдуллова Ләйсән, 4-а сыйныф***

**КОТЛЫЙБЫЗ!№2, 2018 ел**

**Яшь нәфиссүзосталарының “Тере классика” Бөтенроссия конкурсының район этабы туры**



...их урта мәктәбендә үткәрелде. Бе- лем бирү учреждениеләре укучылары чәчмә әсәрләрне сән- гатьле уку буенча ярышты. Классикны сайлау хокукы кат- ...ән иде. Балаларүзләренәякын һәм ошаган әсәрләрне сөйләде- әлеге проектның принципы шундый иде.Конкурсантлартарафыннан теләсә нинди креатив хупланды.Алар чыгыш ясаганда төрле костюмнардан, музыкадан файдалана, әсәрләрдән өзекләрне мини-спектакль рәвешендә һәм башкача тәкъдим итә ала иделәр. Конкурс татар, рус, чуваш телләрендә үткәрелде. Безнең гимназиянең башлангыч сыйныф укучылары да актив кат-катнашып I, II, III дәрәҗәдәге Мактау Грамоталары белән бүләкләнделәр.Аларга киләчәктә дә зур уңышлар телибез.

**“Җәлил укулары-2018”**



9 нчы ноябрь көнне Буа шәһәре Үзәк китапханәсендә «Җәлил укулары» I Халыкара әдәби бәйгесенең 2 нче туры үткәрелде. Биредә безнең мәктәп укучылары да актив катнашты. Укучылар Муса Җәлил әсәрләрен татар, рус һәм төрле халык телләрендә башкардылар; Муса Җәлил,яшь җәлилчеләргә багышлап үзләре язган шигырьләрен сөйләделәр; шагыйрь әсәрләренә

багышлап ясалган рәсемнәрен тәкъдим иттеләр.3 нче турга узучы укучылар:

1.Сабирҗанов Илназ(“Яшь җәлилчеләр “ номинациясе)

2.Хәйруллин Данил(“Рәсем иҗаты” номинациясе)

3.Никонорова Екатерина (“Муса Җәлил рус телендә” номинациясе)

Аларга уңышлар теләп калабыз



**“Шәҗәрәләр – нәсел агачы” конференциясе**

15 нче ноябрьдә Р.Сәгъдиев исемендәге мәктәптә “Шәҗәрәләр – нәсел агачы” V төбәкара фәнни-гамәли конференция булып узды. Бу конференциядә 8-б сыйныф укучысы Хәсәнова Лилия, 9 нчы сыйныф укучысы Кузьмина Полина **2 урын**ны яуладылар. Аларга Мактау Грамотасы һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.



**“Тату сыйныф серләре-2018”**

**28 нче октябрьдә“**Тату сыйныф серләре" ата-аналар комитеты республика бәйгесенең муниципаль этабында безнең Гимназиянең 5 –б сыйныф укучылары һәм аларның эти-әниләре катнашты. Бәйге өч этаптан торды: "Тату сыйныф серләре" күргәзмәсе, визит карточкасы һәм "Гаилә һәм мәктәпнең үзара мөнәсәбәте: проблемалар һәм аларга чишелеш табу" проектын яклау. Әлеге бәйгедә алар “Дус һәм бердәм сыйныф” номинациясендә җиңүче булдылар.







**ТӨРЛЕЛӘР№2, 2018**





***Рәсем күргәзмәсеннән***

Ел саен 9 декабрьдә Халыкара коррупциягә каршы көрәш көне билгеләп үтелә. Коррупция – барлык җәмгыятьләрдә социаль-икътисадый үсешне какшата торган җитди җинаять ул. Әлеге Халыкара көнне гамәлгә куюның максаты - коррупция проблемасын һәм коррупцияне кисәтү, аңа каршы көрәштә Конвенциянең ролен тирәнрәк аңлауны барлыкка китерү.

*******



**<u>Редколлегия составы:</u>**

**Баш мөхәррир** – Гайнетдинова Э. Т.

Газета өчен материал туплаучылар

һәм текстны җыючылар:4,6,8 сыйныф укучылары.

***Безнең адрес***: Буа шәһәре,Г. Исхакый урамы, 29

***Телефон*:** 8(84374) 3-63-90